| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОКУВАКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ КУАК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2023 елның 18 декабреннән Иске Куак авылы № 47

«Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 42 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Иске Куак авыл җирлеге" муниөипаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 42 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.6 пунктының икенче абзацында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

4.10 пункт гамәлдән чыккан дип танырга;

4.13 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4.13. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турындагы карар, әлеге Нигезләмәнең 4.7 пунктының 2 абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, сыйныф чинын барлык кирәкле документлар белән җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына бирү турында тапшыру кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкина ур., 36, адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Н. Сушкова